*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа гомуми үсеш бирү төрендәге “Балачак” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*



# Чишмә башы

*№ 4*

*Декабрь , 2025 ел*



***Ата-аналар һәм балалар өчен кызыклы мәгълүматлар***

## «Кышкы табигать»

**Кыш – ел фасылының иң салкыны. Алтын көз үтүгә, таягына таянып, ап-ак сакалын җирдән сөйрәп, кунакка кыш килә. Килә дә җир өстенә күбәләк-күбәләк карлар яудыра. Кар бөртекләре, җемелдәшеп, бер-берсе белән уйнап, җиргә коелалар. Шулай итеп, кыш үзенең келәмен җәя. Көннән-көн соңрак чыккан кояш та салкынча елмая. Кыш үзенең аклыгы, сафлыгы белән матур.**

**Кырлар, яз җиткәнче ап-ак юрганга төренеп, тыныч кына тирән йокыга талганнар. Салкын көннәрдә агачлар бәс белән каплана. Бөтен дөньяда матурлык, аклык, сихри тынлык хөкем сөрә.**

**Кышкы табигать искиткеч матур, агач буйларыннан узып киткәндә, үзеңне әкияттәгедәй хис итәсең. Андагы гүзәллекне сүзләр белән генә әйтеп бетерерлек түгел. Песнәкләрнең агач очыннан килеп җитәр-җитмәс нәзек авазлары һәм урман гайбәтчесе – саесканның, юк хәбәрне бар итеп, агачтан агачка сикергәләп, чыркылдап йөрүе генә кышкы табигатькә бераз җанлылык өрә. Матур кышкы кунакларыбыз – кызылтүшләр инде октябрь ахырында ук килеп җиткәннәр иде. Безнең кышкы урманнар, бакчалар бу матур кошлардан башка бик ямансу булыр иде.**

**Авыл,урман-кырлар өстендә кышкы тантаналы тынлык. Тик басу-кырлар өстеннән туктаусыз агылып торган җәяүле буран гына һәр төбәктә кышкы кырыс тәртипләрнең ныклыгын күзәтеп, барлап йөри. Кыш айлары үзенең чеметкеч салкыннары, күз ачкысыз бураннары белән истә кала. Әлеге күренешне тәрәзәдән күзәтеп торуы матур. Үзеңне сихри әкияти бер дөньяга эләккәндәй хис итәсең. Ул тәрәзә пыяласындагы рәсемнәрдә нәрсә генә ясалмаган: чыршы, кар бөртекләре, биек таулар, чәчәкләр дә күрергә була. Табигатьне оста рәссам дип тә атарга мөмкин...**

# «Кышкы чорда куркынычсызлык чаралары.»

Кыш - тылсымлы вакыт. Кыш - хуш исле чыршылар, күңелле бәйрәмнәр вакыты. Ләкин кыш үз куркынычларын китерә. Елның салкын вакытында иминлекне саклау өчен рекомендацияләр.

1. Кояштан саклаучы крем файдаланыгыз – балаларның тәнен кояшның зарарлы нурларынан җәйге чорда гына түгел кышкы айларда да сакларга кирәк. Кояшның нурлары кар яки боздан чагылуы биткә зарарлы, хәтта туры нурлардан кебек.

2. Баланы урамга ничек дөрес киендерергә: баланы урамга җибәргәнче аның ничек киенгән карагыз: җылы, берничә кат кием. Мөмкин кадәр йонлы киемнәр сайлагыз. Йон нык һәм сыгылмалы материал. Кышкы кием баланың зурлыгына туры килергә тиеш һәм хәрәкәтләрне чикләргә тиеш түгел. Бу аеруча аяк киемнәре өчен актуаль. Артык кысан итекләр кан басымын тарайталар, нәтиҗәдә аяклар тизрәк суыналар. Аяк киемен сайлаганда бер размерга зуррак алыгыз. Итекләр су үткәрмәүчән булырга тиеш.

3. Чанада шуу: Балалар чанада шуарга яраталар, шуу чанада , ләкин алар иминлек кагыйдәләрен белергә тиеш. Чанада шуатырган урын ачык булырга тиеш. Баланың юлында агачлар һәм куаклыклар булмаска тиеш. Шулай ук тауның ахыры транспорт юлына чыгарга тиеш түгел.

4. Туңу билгеләре: Ешрак борын, колаклар, яңаклар һәм бармаклар туңа. бөтенесе азапланалар борын, колаклар, яңаклар һәм бармаклар. Туңу билгеләре: кымырҗу, телсезләнү, чәнчеп алу яки пешерү. Җәрәхәтләнгән өлешләр агара, кызара яки зәңгәр була.

5. Әгәр дә бала өшесә:- иң беренче җылы урынга барырга вәҗеп;- җәрәхәтләнгән өлешләрне чиста йомшак тукыма белән уыгыз, кар белән умагыз;- салкын һәм юеш киемнәрне коры, йомшак, иркен киемгә алыштырыгыз;- организмны акрынлап җылытыгыз: какао яки чәй эчерегез;- ярдәмгә табипны чакырыгыз.

6. Шарф, бияләйләр һәм перчаткалар. Шарфны кием эченә кертеп калдырыгыз. Өстәмә бер кием перчаткалар яки бияләйләр булырга тиеш, чөнки перчатка югалырга, яки чыланырга мөмкин.

Саф һавада уеннар чыныгу һәм профилактика өчен бик мөһим. Ләкин урамга чыгар алдыннан яхшылап әзерләнегез.





# « Светофорда кунакта »



Безнен балалар бакчасында зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме белән « Светофорда кунакта» исеме астында күнелле КВН уеннары булып узды.

Чара барышында балалар «Юлда булсаң, бул өлгер, юл кагыйдәсен нык бел!» дигән девиз астында чыгыш ясадылар. Чараның максаты булып, балаларның юл билгеләрен аера белүне, юлда хәвефсезлек кагыйдәләрен өйрәтүне дәвам итү, юлларда күзәтүчәнлекне, игътибарлылыкны, мөстәкыйль фикерләүне үстерү, урамда, җәмәгать транспортында үз-үзеңне тоту культурасы тәрбияләү иде.

Балалар өч командага бүленеп, табышмакларга җавап бирделәр, юл билгеләрен таныдылар, экран аша презентация карап, үзара көч сынаштылар. Махсус машиналар да йөрделәр. Чарада Арча районы ЮХИДИ бүлегенең профилактика буенча җитәкчесе Мухаметзянова Энҗе Газизовна да катнашты. Балалар бакчасында ЮХИДИ хезмәткәрләре катнашында ачык чаралар еш уздырыла.














***Һәр җирдә дә, һәркайда да***
***Белик юл кагыйдәсен.***
***Һичбер истән чыгармыйк***
***Без олыларның сүзен.***



# «Атна вакыйгалары»



3 декабрь илебез территориясендә яки аннан читтә сугыш хәрәкәтләрендә һәлак булган Россия һәм совет сугышчыларының хәрби батырлыгын мәңгеләштерү көне булып тора.
Шул уңайдан, безнең балалар бакчасында балалар белән « Без сине хәтерлибез, Билгесез солдат» дигән темага әңгәмә үткәрелде. Чарада балалар әлеге истәлекле датаның барлыкка килү тарихы белән таныштылар, ни өчен нәкъ менә 3 декабрьдә Хәрби батырлык истәлеген саклау өчен сайланганын белделәр, Тәрбияче «Билгесез солдат»һәйкәле турында сөйләде. Хәтер китабы белән таныштырды. Чара ахырында балалар билгесез солдатны искә алу көне хөрмәтенә кәгазь битләренә «Мәңгелек ут» рәсемен ясадылар.
Без бу истәлекне буыннан-буынга тапшырырга һәм сакларга тиешбез. Сугыш кырларында һәлак булучылар истәлегенә Мәңгелек хәтер!



9 декабрь - «Халыкара коррупциягә каршы көрәш көне». Шул уңайдан безнең балалар бакчасында « Стоп- коррупция » исеме астында тематик әңгәмә уздырылды. Тәрбияче балаларны әкият аша намуслы, гадел булу төшенчәләре белән якынрак таныштырды. Әкият геройларының уңай һәм тискәре якларын анализлап нәтиҗә ясалды.



« Коррупциягә каршы көрәш» атналыгы кысаларында, балалар белән «ЮХИДИ хезмәткәре» сюжетлы-рольле уенын уйнадык.

**«Коррупциягә каршы көрәш»** атналыгы кысаларында балалар белән « Төлке һәм кәҗә »әкияте персонажлары аша балаларга дөресен сөйләргә өйрәтү, алдауга тискәре мөнәсәбәт тәрбияләү .





**12 декабрь-« Россия Конституциясе көне! »**
Шул уңайдан зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркемендә Ватан, дәүләт символлары, барлык кешеләрнең хокуклары һәм бурычлары булуы турында әңгәмә узды.

# «Могҗизалы Яңа ел»

Яңа ел һәр йортта, һәр гаиләдә көтеп алынган бәйрәм. Яңа ел һәрвакыт могҗиза, мажаралар һәм гаҗәеп үзгәрешләр бүләк итә.

Балалар бакчасында бәйрәмгә әзерлекне алдан ук башладык.: инсценировка төзедек, костюмнар әзерләдек, бергәләп залны бизәдек.Бәйрәмгә кунаклар бик күп килде. Кыш бабай, Кар кызы килү белән җыр һәм бию, уен - көлке, чын бәйрәм башланды.Барлык балалар рәхәтләнеп үзләренең талантларын күрсәттеләр: биеделәр, әйлән - бәйлән әйләнделәр, шигырьләр сөйләделәр, җырлар җырладылар. Кыш бабай кулыннан балаларга бирелгән бүләкләр шатлык хисләре уятты. Балалар күчтәнәчләрне рәхмәт әйтеп алдылар.

Бәйрәмдә әкият геройлары булып киенеп катнашкан бакча хезмәткәрләренә дә бик зур рәхмәт. Бәйрәм бик күңелле, шатлыклы узды, бик матур тәэсирләр калдырды.


Яңа 2026 нче ел илебезгә тынычлык, шатлык, куанычлар гына алып килсен иде.

















# Безнең уңышлар




# Туган көн белән котлыйбыз!

Декабрь аенда зурлар төркеменә йөрүче егетләребез Шәһиев Самат, Рәхимов Ризат, матур кызыбыз Җиһаншина Ралинә туган көннәрен билгеләп үттеләр. Балаларга сәламәт, озын гомерле, бәхетле, акыллы, тәүфыйклы булып үсүләрен теләп калабыз.







***Газетаны оештыручы һәм баш мөхәррир:*** *Хөсәенова Р.Н, Галиуллина А.Ф.*
***Редколлегия әгъзалары****: Гафурова Р.А., Шагиева А.К., Гафурова Э.Р.*
*Адрес: 422018 ТР,Арча районы, Наласа авылы, Үзәк урам, 76 йорт*